# Sadri Hamid (English)

*Translation Sabira Stahlberg*

*Sadri (Saderdin, "Sertuk") Bäderdin ulı Hamid (Aktuk, 11.10.1905 – Helsinki 14.12.1987) was born in the Tatar village Aktuk at end of the tumultuous year 1905. Aktuk (Russian Aktukovo) or Yañı par (Yañapar), as its inhabitants preferred to call it, is located south of Nizhny Novgorod, some 18 km southwards along the road from Sergach railway station on the Moscow–Kazan line. The land is fertile black soil and the area is inhabited mainly by Tatars, Mordvinians and Russians who live in villages.*

*Sadri Hamid arrived in Finland at the beginning of the 1920s and kept a shop to support his family. In his free time he published the popular magazine Ak Yol / Ak Yul and wrote and published dozens of articles and books in Tatar. Sadri Hamid's life and activities are told by his elder son Ilhan Hamid as follows:*

When the adolescent Sadri, actually still a young boy, left his home village, he did not imagine that he would spend the rest of his life far away. His home and family remained back there – father, mother and siblings.

Life in the village had in many aspects turned to the worse: the once great tsarist Russia suffered from oppression and lack of safety after the revolution, not to mention drought and difficulties to acquire proper grain seeds, causing insurmountable troubles to the farmers of the productive black soil. Money had lost its value and the civil war affected the inhabitants of Aktuk, too. Supplies could be obtained – if one was lucky or suitable "goods for exchange" could be found. Worries permeated the society.

The rails in Finland and Russia are of the same width. The railways were already developed and one could reach even the Pacific coast or Murmansk (Sadri did probably not know these areas yet). Travelling by train was considered safe, as long as the passenger carried a passport and other necessary documents. For the trip also food was necessary. Clothing was simple, like people dressed at that time: one must not draw attention to oneself, but be very careful every moment of the journey.

What did Sadri think of his future? Far away in independent Finland already lived his family's Kulik relatives. Trusting in his God, Allah, he also decided to leave, to become an emigrant in Finland with his relatives, because the near future in his home village looked dark. The wish to live somewhere else and acquire a better life tempted him, even when he had to travel far by railway. This had already for a long time been an attractive goal.

As a young man, he wished to earn enough to survive. The village of Aktuk had been lively and stories about various places outside it were often told: "Somewhere over there, some other time and something there…" are common dreams of youth everywhere in the world. Sadri's expectations were fairly modest, but the dream of a family of his own lived in some nook of his mind.

The dream of establishing a family of his own was fulfilled, when Sadri Hamid and Hayat Shahmayeva were married in Oulu in 1944. Hayat was a Tatar girl born in Narva. She also had relatives in Finland and had fled there by boat when the Soviet Union attacked Estonia.

The couple lived in Oulu and two sons were born, Ilhan (1945) and Balker (1948), who were educated and as adults diligently worked in demanding professions. From 1973 Sadri lived with his family in the capital Helsinki and participated in the social and religious life of his own Tatar minority. But before that…

Sadri spent the greater part of his life with his family in Oulu. At first he peddled and sold at markets in various parts of Northern Finland. Later he worked as a respected entrepreneur and was the owner of two fairly small textile and haberdashery shops.

In addition to shopkeeping, Sadri had literary pursuits and various hobbies. As a co-founder and honorary member of the Oulu philatelist club (stamp collectors, founded in 1930), he participated actively in its work for many years. In the 1960s, he was awarded with a bronze medal for a stamp exhibition in Finland and in the USA with a diploma.

Among handicrafts, working with wood and painting pictures as well as drawing were close to Sadri's heart. He was also interested in numismatics, that is old coins from various countries. Further, he followed closely the daily news and social issues both in Finland and abroad. Sadri is however best known as a productive self-publishing author and poet. The most popular publication is probably the magazine Ak Yol / Ak Yul (literal translation "White Road", but the expression has several other meanings in Tatar). Sadri was its editor-in-chief between 1967 and 1977 and published a total of 63 issues.

Sadri wrote all articles by hand in Arabic script and then duplicated the sheets using offset techniques. From Germany he ordered Arabic types, which he set into printing sheets. Kirjola Oy press in Oulu took care of the printing of his publications. The use of Arabic script was natural and also important for Sadri – this is evident from many opinions expressed in his writings. In addition to magazine production he wrote an impressive number of books and brochures on various subjects.

In Sadri's life, the love for his own language and Tatar culture was strong. His numerous writings about his home village, its nature and life, are proof of this. His character is remembered as a true treasure chest of clever puns, poems and rhymes, and short, humorous stories.



# Sadri Hamid (suomeksi)

*Sadri (Saderdin, ”Sertuk”) Bäderdin ulı Hamid (Aktuk, 11.10.1905 – Helsinki 14.12.1987) syntyi Aktukin tataarikylässä myllerrysten vuoden 1905 lopulla. Aktuk (venäjäksi Aktukovo) eli Yañı par (kirjoitetaan myös Yañapar) sijaitsee Nižni Novgorodin eteläpuolella. Moskovasta Kazaniin päin junalla mentäessä Sergatshin asemalta on matkaa vielä noin 18 km maantietä pitkin etelään. Alue on viljavaa mustanmullan maata ja seutu on tataari-, mordvalais- ja venäläiskylien asuttamaa.*

*Sadri Hamid tuli Suomeen 1920-luvun alkupuolella ja elätti perheensä kauppiaana. Vapaa-aikanaan hän toimitti suosittua* Ak Yol / Ak Yul*-lehteä sekä kirjoitti ja julkaisi kymmeniä artikkeleita ja kirjoja tataariksi. Sadri Hamidin elämästä ja toiminnasta kertoo hänen vanhempi poikansa Ilhan Hamid seuraavasti:*

Eipä olisi murrosikäinen Sadri, itse asiassa vielä poikanen, uskonut kotoa lähtiessään jättävänsä synnyinkylänsä loppuelämäkseen. Sinne jäivät koti ja lähiomaiset – isä, äiti ja sisarukset. Elämä kylässä oli muuttunut monellakin tavalla huonoksi.

Aiemmin niin suuri tsaarin Venäjä oli joutunut vallankumouksen jälkeisen sorron ja turvattomuuden aikaan, puhumattakaan siitä, että kuivuus ja hyvän, kunnon siemenviljan saannin puute olivat aiheuttaneet mustanmullan runsassatoisille pelloille ylitsepääsemättömiä ongelmia. Raha oli menettänyt arvonsa ja sisällissota vaikutti myös Aktukin kyläläisiin. Tarvikkeita sai, jos oli onnea tai jos sopivaa ”vaihdettavaa tavaraa” löytyi. Yleinen ahdistuneisuus oli vallannut koko yhteiskunnan.

Rautatiekiskot Suomessa ja Venäjällä ovat samanlevyisiä. Junaliikenne oli jo tuolloin kehittynyttä ja junalla pääsi Tyynenmeren rannikolle tai Murmanskiin asti (Sadri ei tosin varmaankaan näitä alueita vielä tuntenut). Junalla matkustamista pidettiin turvallisena, kunhan oli passi ja muut tarvittavat asiakirjat. Matkaa varten oli tapana ottaa omat eväät mukaan. Vaatetus oli yksinkertaista, sen ajan mukaista. Huomiota ei saanut herättää ja varovainen piti olla joka käänteessä.

Mitähän Sadri mahtoi ajatella tulevaisuudestaan? Kaukana itsenäistyneessä Suomessa asui jo tuolloin hänen omaa Kulikin sukua. Luottaen Jumalaansa, Allahiin, hänkin päätti lähteä siirtolaiseksi sukulaistensa luo Suomeen, koska lähitulevaisuus kotikylässä näytti synkältä. Halu elää jossain muualla ja saada parempi elämä pitkienkin rautatiematkojen päässä houkutteli häntä ja oli houkutellut jo kauan.

Nuorena miehenä hänellä oli halu ansaita sen verran, että tulisi toimeen. Aktukin kylä oli ollut vireä ja tarinoita eri paikoista oli kuultu runsaasti: ”Siellä jossain, siellä joskus ja siellä jotain…” ovat eri puolilla maailmaa elävien nuorten yhteisiä haavekuvia. Sadrin vaatimukset olivat melko pienet, mutta unelma omasta perheestä oli jossakin mielen sopukassa.

Haave oman perheen perustamisesta toteutui, kun Sadri Hamid ja Hayat Shahmayeva vihittiin avioliittoon Oulussa vuonna 1944. Hayat oli Narvassa syntynyt tataarityttö, jolla myös oli sukulaisia Suomessa. Hän oli tullut Suomeen veneellä pakoon Neuvostoliiton hyökkäystä Viroa vastaan.

Pariskunta jäi asumaan Ouluun ja perheeseen syntyi kaksi poikaa, Ilhan (1945) ja Balker (1948). He kouluttautuivat ja toimivat ammateissaan vaativissa tehtävissä. Vuodesta 1973 Sadri asui perheineen Helsingissä ja osallistui oman tataarivähemmistönsä sosiaaliseen ja uskonnolliseen elämään. Mutta ennen sitä…

Suuren osan elämästään Sadri vietti perheensä kanssa Oulussa. Hän harjoitti aluksi kulku- ja torikauppaa toreilla ja markkinoilla eri puolilla Pohjois-Suomea. Myöhemmin hän toimi arvostettuna yksityisyrittäjänä kahden pienehkön kangas- ja lyhyttavaraliikkeen omistajana.

Kaupankäynnin ohella hänellä oli kirjoittamisen lisäksi monia eri harrastuksia. Oulun postimerkkikerho r.y.:n (perustettu 1930) perustaja- ja kunniajäsenenä hän oli monen vuoden ajan aktiivisti mukana seuran toiminnassa. Hänet palkittiin pronssimitalilla 1960-luvulla postimerkkinäyttelystään Suomessa ja kansainvälisesti USA:ssa kunniakirjalla.

Kädentaidoista puukäsityöt ja taulujen maalaaminen sekä piirtäminen olivat lähellä Sadrin sydäntä. Hän oli kiinnostunut myös numismatiikasta eli eri maiden vanhoista rahoista. Lisäksi hän seurasi tiiviisti päivän uutisia ja yhteiskunnallisia asioita niin kotimaassa kuin muualla maailmassakin.

Sadri tunnetaan kuitenkin parhaiten tuotteliaana omakustannuskirjailijana ja runoilijana. Hänen tuotannostaan suosituin lienee *Ak Yol / Ak Yul* (kirjaimellinen käännös on ”Valkoinen tie”, mutta ilmaisulla on useita muitakin merkityksiä tataariksi) nimellä ilmestynyt lehtinen, jonka päätoimittajana hän toimi vuosina 1967–1977, ja josta ilmestyi yhteensä 63 numeroa.

Kaiken Sadri kirjoitti käsin arabialaisilla kirjaimilla ja monisti sitten arkit offsettekniikalla. Hänellä oli käytössä myös Saksasta tilaamansa arabialaiset kirjasimet, jotka hän latoi painoarkeiksi. Kirjola Oy:n kirjapaino Oulussa hoiti julkaisujen painotyöt.

Arabialaisten kirjainten käyttö oli Sadrille luontaista ja myös tärkeää – tämä tulee ilmi useina kannanottoina hänen tuotannossaan. Lehtituotannon lisäksi hän kirjoitti kunnioitettavan määrän kirjoja ja eri aiheisiin liittyviä lehtisiä.

Sadrin elämässä rakkaus omaan äidinkieleen ja tataarikulttuuriin oli voimakasta. Sen todistavat lukuisat kirjoitukset synnyinkylästä, sen luonnosta ja elämästä. Hänen persoonansa muistetaan varsinaisena aarrearkkuna taitavista sanaleikeistään, runoistaan ja riimeistään sekä huumorintäytteisistä pakinoistaan.



# Sadri Hamid

*Tärcemä: Fazile Nasretdin*

*Sadri (Saderdin, ”Sertuk”) Bederdin ulı Hamid (Aktuk, 11.10.1905–Helsinki, 14.12.1987) bolgavır zamanınıñ 1905 ahırında, Aktukta (rusçası Aktukovo), Yañı par (Yañapar) iseme belän dä tanılgan, tatar avılında tugan. Bu avıl Tübän Novgorod ölkäseneñ könyagında. Mäskäüdän Kazanga puyız belän barganda Aktukka iñ yakın tuktalış Sergaç şähäre. Bu tuktalıştanavılga citär öçen tagın uram buylap yakınça 18 km könyakka taba barırga kiräk. Töbäk uñışlı kara tufrak cirläre, häm bu yaklarda tatar, rus häm mukşı avılları yäşi.*

*Sadri Hamid 1920 yıllar başlarında Finlandiyägä kilep, säüdägärlek eşe belän ailäsen yäşätte. Buş vakıtında ul yaratılgan* Ak yol / Ak yul *isemle jurnal, bik küp mäkalälär häm kitaplar tatar telendä yazıp, bastırıp taratttı. Sadri Hamidnıñ tormışı häm eşçänlege turında olı ulı İlhan Hamid tübändä söyli:*

Yäşüsmer Sadri, çınnan da äle malay gına, öydän çıkkanda, tugan avılın omere buyına kaldıraçagına ışanmagandır. Öy, yakın tugannar – äti, äni häm enelär anda kaldı.

Avıldagı tormış küp yaktan naçaraygan ide. Elegräk bik böyek patşa Räsäye bulgan däülät inkıylaptan soñ tärtipsezlekkä häm kurku tulı çorga eläkkän ide. Östävenä korılık häm dä yahşı aşlık orlıklarınıñ tabılmavı, elektän mul uñışlı, kara tufraklı kırlar öçen çişep almaslık avırlıklar tudırgan ide. Akçanıñ kimmäte yugalgan, häm vatandaşlar sugışı Aktuk avılınıñ halkına da täesir itkän ide. Bäheteñ bulsa yäki ”alıştırıla torgan tavarıñ” tabılsa, kiräk-yaraklar alırga mömkinlek bar ide. Omumi tınıçsızlanu böten cämiyätne häm yaulap algan ide.

Finlandiyä häm Rusiyä timer yulları berük kiñlektä. Puyız transportı ul vakıtta inde alga kitkän bulgan. Puyız belän hattä Tın okean yarlarına yäki Murmanskka kadär barıp bula ide (gärçä Sadri bu yaklarnı belmägän bulsa da). Pasport häm başka kiräkle dokumentlar bulganda puyız belän säyähat itü kurkınıçsız sanala ide. Yul öçen üz rizıkarnı alu adätkä kergän ide. Ös-baş kiyenü adi gına, dimäk, ul zamanga kürä häm härvakıt sak bulıp yörergä kiräk ide.

Sadri üzeneñ kiläçäge turında närsä uylagandır. Kardäşlär, Kulik näselennän bulgan tugannarı, yırakta bäysez Finlandiyädä yäşi ide inde. Allahına ışanıp, ul Finlandiyädäge tugannarı yanına küçep kitärgä karar kıldı, çönki tugan avılının, Aktuknıñ, yakın kiläçäge karañgı bulıp kürende. Başka cirdä yäşäü häm yahşırak tormışka omtılu teläge, timer yulı belän yırak cirlärgä baru, anı küptän inde kızıktırıp tora ide.

Yeget çagında yalgız kirägenä tikle genä akça kazanu anıñ teläge ide. Aktuk avılı canlı bulıp, anda törle yak hikäyäläre gel işetelep torgan. ”Kaydadır, kayçandır, närsäder...” – yani dönyanıñ törle poçmaklarında yäşäyçe yäşlärneñ urtak hıyalları. Sadri Hamidnıñ tormış öçen taläpläre şaktıy adi bulgan, ämma ailä koru hıyalı kaydadır küñeleneñ ber poçmagında yäşi kilgän.

Ailä koru hıyalı Ouluda 1944 nçe yılda Hayat Şahmayeva belän nikahlangaç çınga äverelde. Hayat Narvada tugan tatar kızı ide, häm anıñ da tugannarı Finlandiyädä yäşi ide inde. Ul, Sovyetlar Berlege Estoniyägä höcüm itkännän, köymä belän Finlandiyägä kaçıp kitkän bulgan.

Yäş par tormışların Ouluda kordılar. Ailägä ike ir bala nasıyp buldı, İlhan (1945) häm Balkır (1948). Alar ikese dä belem aldılar häm üz hönärlärendä cavaplı eşlär alıp bardılar. Omereneñ soñgı öleşen, 1973 nçe yıldan başlap, Sadri Hamid Helsinkidä ailäse belän yäşäde häm tatar azçılıgınıñ ictimai-dini tormışında katnaştı. Läkin monnan elek...

Sadri omereneñ zur öleşen ailäse belän Ouluda ütkärde. Başta tönyak Finlandiyäneñ törle poçmaklarında uzılçı (küçmä satuçı) bulıp annarı törle bazarlarda häm yärminkälärdä säüdä kıla ide. Soñrak ike keçkenäräk tukıma kibeteneñ hucası, hormätle eşkuar, bulıp eşläde.

Säüdägärlek häm yazu hönärennän tış küp başka hobbiları da bar ide. Yıllar buyı Ouludagı poçta markası klubında (1930 yılda korılgan) koruçı häm maktaulı aza bularak aktiv katnaştı. Sadri 1960 nçı yıllarda Finlandiyädä poçta markası kürgäzmäse öçen bronza medal häm AKŞ ta halıkara çarada maktaulı sertifikat belän büläklände. Kul eşlärennän agaç hönärläre, buyau häm räsem yasau yörägenä yakın ide. Ul şulay uk numizmatika, dimäk, törle illärneñ borıngı akçaları, belän kızıksına ide. Härkönlek kızıksınuı Finlandiyä häm başka illärneñ dönyavi habärläre häm vakıygaları ide.

Läkin Sadri Hamid, ädip häm şair bularak, iñ yahşı üze baskan, kiñkolaçlı ädäbi äsärlärennän tanıla. Anıñ icatında iñ yaratılganı, bälki dä, *Ak Yol / Ak Yul* ( ”ak” häm “ak yul” tatar telendä berniçä mäganägä iyä) dip isemlängän jurnalı. Ul anı 1967–1977 arasında baş möharrir bulrak näşer itte, häm 63 san bastırıp taratttı.

Bar äsärlären aräp hareflärendä kul belän yazıp, annarı ofset teknologiyäse yärdämendä kübäytä ide. Almaniyädän zakaz itep algan aräp şriftların da kullandı. Alarnı basmaga cıyıp, Kirjola Oy basmahanäsendä, Ouluda, bastırıp tarata ide. Aräp hareflären kullanu Sadri öçen tabi’i häm möhim ide. Bu turıda ul uy-fikerlären icatında açık itep kürsätä. Jurnaldan tış, ul küp kitaplar häm törle temalarga kagışlı cıyıntıklar citeşterde.

Sadri Hamidnıñ ana telenä, tatar telenä häm mädäniyätenä mähabbäte köçle ide. Monı tugan avılı, anıñ tabigate häm tormışı turındagı küp yazmaları raslıy. Anıñ şähese icatınıñ akıllı süz uynatkıçları, kölkele mäzäkläre, eçtälekle şigırläre häm osta rifmaları belän çın hazinä sandıgı bulıp istä kala.



# Садри Хамид

*Тәрҗемә: Фазилә Насретдин*

*Садри (Садердин, «Сертук») Бәдердин улы Хәмид (Актук, 11.10.1905 – Хельсинки 14.12.1987) болгавыр заманының 1905 ахырында, Актукта (русчасы Актуково), Яңы пар (Яңыпар) исеме белән дә танылган, татар авылында туган. Бу авыл Түбән Новгород өлкәсенең көньягында. Мәскәүдән Казанга поезд белән барганда Актукка иң якын тукталыш Сергач шәһәре. Бу тукталыштан авылга җитәр өчен тагын урам буйлап якынча 18 км көньякка таба барырга кирәк. Төбәк уңышлы кара туфрак җирләре, һәм бу якларда татар, рус һәм мукшы авыллары яши.*

*Садри Хәмид 1920 еллар башларында Финляндиягә килеп, сәүдәгәрлек эше белән гаиләсен яшәтте. Буш вакытында ул яратылган «Ак Йол / Ак Юл» исемле журнал, бик күп мәкаләләр һәм китаплар татар телендә язып, бастырып таратты. Садри Хәмиднең тормышы һәм эшчәнлеге турында олы улы Илхан Хәмид түбәндә сөйли:*

Яшүсмер Садри, чыннан да әле малай гына, өйдән чыкканда, туган авылын гомере буена калдырачагына ышанмагандыр. Өй һәм якын туганнар – әти, әни һәм энеләр анда калды.

Авылдагы тормыш күп яктан начарайган иде. Элегрәк бик бөек патша Рәсәйе булган дәүләт инкыйлаптан соң тәртипсезлеккә һәм курку түлы чорга эләккән иде. Өстәвенә корылык һәм дә яхшы ашлык орлыкларының табылмавы, электән мул уңышлы, кара туфраклы кырлар өчен чишеп алмаслык авырлыклар тудырган иде. Акчаның кыйммәте югалган, һәм ватандашлар сугышы Актук авылының халкына да тәэсир иткән иде. Бәхетең булса яки «алыштырыла торган товарың» табылса, кирәк-яраклар алырга мөмкинлек бар иде. Гомуми тынычсызлану бөтен җәмгыятьне яулап алган иде.

Финляндия һәм Русия тимер юллары берүк киңлектә. Поезд транспорты ул вакытта инде алга киткән булган. Поезд белән хәтта Тын океан ярларына яки Мурманскка кадәр барып була иде (гәрчә Садри бу якларны белмәгән булса да). Паспорт һәм башка кирәкле документлар булганда поезд белән сәяхәт итү куркынычсыз санала иде. Юл өчен үз ризыкларны алу гадәткә кергән иде. Өс-баш киенү гади генә, димәк, ул заманга күрә һәм һәрвакыт сак булып йөрергә кирәк иде.

Садри үзенең киләчәге турында нәрсә уйлагандыр. Кардәшләр, Кулик нәселеннән булган туганнары, еракта бәйсез Финляндиядә яши иде инде. Аллаһына ышанып, ул Финляндиядәге туганнары янына күчеп китәргә карар кылды, чөнки туган авылының, Актукның, якын киләчәге караңгы булып күренде. Башка җирдә яшәү һәм яхшырак тормышка омтылу теләге, тимер юлы белән ерак җирләргә бару, аны күптән инде кызыктырып тора иде.

Егет чагында ялгыз кирәгенә тикле генә акча казану аның теләге иде. Актук авылы җанлы булып, анда төрле як хикәяләре гел ишетелеп торган. «Кайдадыр, кайчандыр, нәрсәдер...» – ягъни дөньяның төрле почмакларында яшәүче яшьләрнең уртак хыяллары. Садриның тормыш өчен таләпләре шактый гади булган, әмма гаилә кору хыялы кайдадыр күңеленең бер почмагында яши килгән.

# Tea Room ▪ Çäyhanä ▪ Чәйханә

Гаилә кору хыялы Оулуда 1944-нче елда Хәят Шахмаева белән никахлангач чынга әверелде. Хәят Нарвада туган татар кызы иде, һәм аның да туганнары Финляндиядә яши иде инде. Ул, Совет Берлеге Естониягә һөҗүм иткәннән соң, көймә белән Финляндиягә качып киткән булган.
Яшь пар тормышларын Оулуда кордылар. Гайләгә ике ир бала насыйп булды, Илхан (1945) һәм Балкыр (1948). Алар икесе дә белем алдылар һәм үз һөнәрләрендә җаваплы эшләр алып бардылар. Гомеренең соңгы өлешен, 1973 нче елдан башлап, Садри Хәмид Хельсинкидә гаиләсе белән яшәде һәм татар азчылыгының иҗтимагый-дини тормышында катнашты. Ләкин моннан элек…

Садри гомеренең зур өлешен гаиләсе белән Оулуда үткәрде. Башта Төньяк Финляндиянең төрле почмакларында «узылчы» (күчмә сатучы) булып аннары төрле базарларда һәм ярминкәләрдә сәүдә кыла иде. Соңрак ике кечкенәрәк тукыма кибетенең хуҗасы, хөрмәтле эшкуар булып эшләде.

Сәүдәгәрлек һәм язу һөнәреннән тыш күп башка хоббилары да бар иде. Еллар буе Оулудагы почта маркасы клубында (1930 елда корылган) коручы һәм мактаулы әгъза буларак актив катнашты. Садри 1960 нчы елларда Финляндиядә почта маркасы күргәзмәсе өчен бронза медаль һәм АКШ та халыкара чарада мактаулы сертификат белән бүләкләнде.

Кул эшлареннән агач һөнәрләре, буяу һәм рәсем ясау йөрәгенә якын иде. Ул шулай ук нумизматика, димәк, төрле илләрнең борынгы акчалары, белән кызыксына иде. Һәркөнлек кызыксынуы Финляндия һәм башка илләрнең дөняви хәбәрләре һәм вакыйгалары иде.

Ләкин Садри Хәмид, әдип һәм шагыйрь буларак, иң яхшы үзе баскан, киңколачлы әдәби әсәрләреннән таныла. Аның иҗатында иң яратылган, бәлки дә, *«Ак юл»* («ак» һәм «ак юл» татар телендә берничә мәгънәгә ия) дип исемләнгән журналы. Ул аны 1967 — 1977 арасында баш мөхәррир буларак нәшер итте, һәм 63 сан бастырып таратты.

Бар әсәрләрен гарәп хәрефләрендә кул белән язып, аннары офсет технологиясе ярдәмендә күбәйтә иде. Алманиядән заказ итеп алган гарәп шрифтларын да кулланды. Аларны басмаларга җыеп, Кирйола Оү басмаханәсендә, Оулуда, бастырып тарата иде.

Гарәп хәрефләрен куллану Садри өчен табигый һәм мөһим иде. Бу турыда уй-фикерләрен ул иҗатында ачык итеп күрсәтә. Журналдан тыш, ул күп китаплар һәм төрле темалага кагылышлы җыеынтыклар җитештерде.

Садри Хәмидның ана теленә, татар теленә һәм мәдәниятенә мәхәббәте көчле иде. Моны туган авылы, аның табигате һәм тормышы турындагы күп язмалары раслый. Аның шәхесе иҗатының акыллы сүз уйнаткычлары, көлкеле мәзәкләре, эчтәлекле шигырьләре һәм оста рифмалары белән чын хәзинә сандыгы булып истә кала.